| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 март Баулы № 200

Татарстан Республикасы «Баулы
муниципаль районы» муниципаль
берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең
этика һәм хезмәт тәртибе кодексын
раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-142нче номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 1100нче номерлы Указлары нигезендә, Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салуны камилләштерү максатларында, Баулы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендә кабул ителгән «Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында» 247нче номерлы карары (Баулы муниципаль районы Советының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән 103нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы

Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы
Советының
2019 елның 27.03.2019
200 кабул ителгән карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе**
**КОДЕКСЫ**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы (алга таба - Кодекс) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы закон, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы закон һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезләмәләре нигезендә эшләнде, шулай ук Россия җәмгыяте һәм дәүләтенең гомуми әхлакый принципларына һәм нормаларына нигезләнгән.

1.2. Кодекс Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар кулланырга тиешле һөнәри хезмәт этикасының һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләренең гомуми җыентыгы булып тора.

1.3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткә (алга таба - муниципаль хезмәт) керүче Россия Федерациясе гражданины Кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм хезмәт эшчәнлеген башкарганда, шул исәптән Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен

кулланып, аларны үтәргә тиеш.

1.4. Һәр муниципаль хезмәткәр Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен барлык кирәкле чаралар күрергә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәр гражданы муниципаль хезмәткәр, аның белән аралашканда, Кодексның нигезләмәләрен үтәвен көтәргә хокуклы.

1.5. Кодексның максаты – муниципаль хезмәткәрләрнең, үз һөнәри эшчәнлекләрен лаеклы үтәү өчен, хезмәт этикасы кагыйдәләрен һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү.

1.6. Кодекс муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз вазыйфаларын башкаруның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

1.7. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә тиешле әхлак формалаштыру, җәмгыяттә муниципаль хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру өчен нигез булып тора.

1.8. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен белү һәм үтәү аларның һөнәри эшчәнлеге һәм хезмәт тәртибе сыйфатын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## II.МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ХЕЗМӘТ ТӘРТИБЕНЕҢ ГОМУМИ ПРИНЦИПЛАРЫ ҺӘМ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдында җаваплылык тоеп, муниципаль хезмәткәрләр тиеш:

а) муниципаль органнарның нәтиҗәле эшен тәэмин итү максатларында, хезмәт вазыйфаларын намус белән һәм югары профессиональ дәрәҗәдә башкарырга;

б) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең төп мәгънәсе икәнлегеннән чыгып эш итәргә;

в) җирле үзидарәнең тиешле органы вәкаләтләре чикләрендә үз

эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

г) нинди дә булса һөнәри яки социаль төркемнәргә һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнарның, һөнәри яки социаль төркемнәр һәм оешмаларның йогынтысыннан бәйсез булырга;

д) вазыйфаи бурычларын намус белән башкаруга комачаулаучы нинди дә булса шәхси, милек (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләрне булдырмаска;

е) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә, муниципаль хезмәт үтүгә бәйле бурычларны үтәргә;

ж) муниципаль хезмәткәр хезмәт эшчәнлегенә сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр йогынты ясау мөмкинлеген бирми торган объективлыкны сакларга;

з) хезмәт, һөнәри этика нормаларын һәм эшлекле тәртип кагыйдәләрен үтәргә;

и) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән мөнәсәбәтләрдә корректлы һәм игътибарлы булырга;

к) Россия һәм башка дәүләтләр халыкларының гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә хөрмәт күрсәтергә, төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара килешүләргә ярдәм итәргә;

л) муниципаль хезмәткәрләрнең үз вазыйфаи йөкләмәләрен намуслы башкаруда шик уятырлык гамәлләрдән тыелып торырга, шулай ук аның абруена яисә җирле үзидарә органы абруена зыян китерә алырлык низаглы хәлләрне булдырмаска;

м) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә юл куймау һәм барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрергә;

н) шәхси мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

о) әгәр бу муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына кермәсә, җирле үзидарә органы, аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата фикер белдерүдән һәм бәя бирүдән тыелып тору, икән;

п) җирле үзидарә органында билгеләнгән гавами чыгышлар һәм хезмәт мәгълүматы бирү кагыйдәләрен үтәргә;

р) массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең дәүләт органы эше турында хәбәр итү эшчәнлегенә хөрмәт белән карау, шулай ук гражданнарга һәм оешмаларга билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат алуда ярдәм күрсәтү;

с) халык каршында чыгышларда, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, Россия Федерациясе территориясендә чит ил валютасында (шартлы акчалата берәмлекләрдә) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр һәм граждан хокукларының башка объектлары бәясен – Россия Федерациясе резидентлары арасында килешүләр суммасы, Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗә бюджетлары күрсәткечләре, муниципаль бурычка алу күләмнәре, муниципаль бурыч күләмен билгеләүдән тыелып торырга (бу мәгълүматны төгәл тапшыру өчен кирәк булган яисә Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясе халыкара килешүләре, эшлекле әйләнеш традицияләре белән каралган очраклардан тыш);

т) үз җаваплылыгы өлкәсендә булган ресурслар белән һәрвакы мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк идарә итәргә омтылырга.

2.1. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үтәргә тиеш.

2.2. Муниципаль хезмәткәрләр үз эшчәнлекләрендә сәяси, икътисадый максатка ярашлылык йә башка мотивлар буенча законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозуга юл куймаска тиеш.

2.3. Муниципаль хезмәткәрләр, гамәлдәге нормаларны һәм билгеләнгән таләпләрне үтәгәндә, хезмәт белән бәйле мәгълүматны эшкәртә һәм икенче затка тапшыра алалар.

2.4. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аларга мәгълүм мәгълүматны санкцияләнмәгән рәвештә игълан итү өчен җавап тота, аның иминлеген һәм кофединциальлеген тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә тиеш.

2.5. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр алар өчен профессиональлек, мактауга лаек репутация үрнәге булырга, җирле үзидарә органында яисә аның бүлекчәләрендә әхлакый климатның нәтиҗәле эшләве өчен уңай шартлар булдырырга ярдәм итәргә тиеш.

2.6. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр, моңа каршы тиешле чаралар күрмәсә, Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенә буйсынган хезмәткәрләрнең этика принципларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен бозучы гамәлләре яки эшләмәүләре өчен җавап тота.

## III. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕҢ КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ҮЗ-ҮЗЕН ТОТУ СТАНДАРТЫ

3.1. Муниципаль хезмәткәрләр коррупция күренешләренә каршы торырга һәм аны профилактикалау буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрергә тиеш.

3.2. Муниципаль хезмәт, вазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларны тиешенчә үтәүгә йогынты ясарлык шәхси кызыксынуы туу мөмкинлеге турында белдерергә тиеш.

3.3.Муниципаль хезмәткәр үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүмат бирергә тиеш.

3.4. Муниципаль хезмәткәр үзен яллаучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына яки башка дәүләт органнарына аңа нинди дә булса затлар коррупциячел хокук бозуга тарту максатларында мөрәҗәгать итүе турында хәбәр итәргә тиеш.

Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать фактлары турында хәбәр итү (бу фактлар буенча тикшерү үткәрелә торган яки үткәрелгән очраклардан тыш) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычы булып тора.

3.5. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи бурычларын башкарган өчен физик һәм юридик затлардан бүләк (әйберләтә яки акчалата бүләк, ссудалар, матди характердагы хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял, транспорттан файдалану өчен түләү формасындагы һәм башка бүләкләр) алу тыела. Рәсми чараларда, хезмәт командировкаларында һәм башкаларда муниципаль хезмәткәрләргә ясалган бүләкләр Татарстан Республикасы милке булып таныла һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан акт буенча, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына тапшырыла.

3.6. Муниципаль хезмәткәрләр бурычлы:

а) башка түләүле эш башкару нияте турында яллаучы вәкиленә алдан хәбәр итәргә;

б) түбәндәгеләргә яллаучы вәкиленнән язма рөхсәт алу мәҗбүри:

- әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана торган түләүле эшчәнлеккә;

- муниципаль хезмәткәр вазифаларына түбәндәге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керсә, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләре, мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнниләрдән тыш) кабул итүгә;

в) әгәр дә аларга ия булу мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булса, муниципаль хезмәткәр карамагында булган кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав капиталы өлешен, пайларны) Россия Федерациясе законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга;

г) матди-техник һәм башка тәэмин итү чараларын, башка дәүләт мөлкәтен бары тик вазыйфаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә генә файдаланырга.

3.7. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр тиеш:

а) үз кул астындагыларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә;

б) хезмәткәрләре арасында коррупцияне булдырмау чараларын күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә катнашырга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска.

3.8. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр үз-үзен тотышы белән намуслылык һәм гаделлек үрнәге күрсәтергә тиеш.

3.9.Бер-берсенә турыдан-туры буйсынган муниципаль хезмәткәрләр арасында якын туганлык (ата-аналары, ире яки хатыны, балалары, абый-сеңелләре, шулай ук иренең яки хатынының бертуганы, сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) булганда аларның берсе муниципаль хезмәттән китәргә яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчәргә тиеш.

## IV.МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ҺӨНӘРИ ХЕЗМӘТ ЭТИКАСЫНЫҢ ГОМУМИ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

4.1. Муниципаль хезмәткәр үз хезмәтендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң кадерле әйбер булып тора һәм һәр гражданин шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын, абруен яклауга хокуклы дигән конституциячел нигезләмәләрдән чыгып эш итәргә тиеш.

4.2. Муниципаль хезмәткәр үз-үзен тотышында түбәндәгеләрдән тыелып калырга тиеш:

а) җенес, яшь, раса, милләт, тел, гражданлык, социаль, финанс яки гаилә хәле, сәяси яки дини карашлар өчен дискриминацион сүзләр һәм гамәлләрдән;

б) дорфалыктан, кимсетүле тонынннан, тәккәберлектән, урынсыз кисәтүләрдән, нигезсез гаеп ташлаудан;

в) нормаль аралашуга комачаулаучы яки хокукка каршы гамәлләргә китерүче янаудан, мыскыллы сүзләрдән;

г) киңәшмә, әңгәмә, гражданнар белән башка хезмәт аралашуы вакытында тәмәке тартудан.

4.3. Муниципаль хезмәткәрләр коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр урнашуга һәм бер-берсе белән конструктив хезмәттәшлеккә ярдәм итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләр әдәпле, игътибарлы булырга һәм гражданнар һәм хезмәттәшләре белән аралашуда түземле, сабыр булырга тиеш.

4.4. Тикшерү уздырган вакытта муниципаль хезмәткәр тикшерелүче оешма җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре белән объектив эш итү сәләтенә йогынты ясый алырлык мөнәсәбәтләргә керергә тиеш түгел.

4.5. Муниципаль хезмәткәр үзенең рәсми статусын өченче як мәнфәгатьләрендә кулланырга тиеш түгел.

## V. НИЗАГЛЫ СИТУАЦИЯЛӘР

5.1. Муниципаль хезмәткәр үз вазыйфаларын башкарганда низаглы хәлләр барлыкка килүгә юл куймаска тиеш.

Муниципаль хезмәткәр үзен лаеклы тотарга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, үзенең вазыйфаи регламенты, шулай ук әлеге Кодексның нормалары нигезендә эшләргә тиеш.

5.2. Муниципаль хезмәткәр конфликтлы ситуацияне булдырмый кала алмаса, конфликт турында җитәкчегә җиткерергә тиеш.

Әгәр турыдан-туры җитәкчесе проблеманы хәл итә алмаса яки низаглы

хәлгә үзе җәлеп ителсә, муниципаль хезмәткәргә бу хакта югарыдагы җитәкчегә хәбәр итәргә кирәк.

## VI. КОДЕКС НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕН БОЗГАН ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫК

6.1. Әлеге Кодексның нигезләмәләрен бозу Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында»гы 2010 елның 25 августында кабул ителгән ПУ-569 номерлы Указы нигезендә барлыкка килә торган мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында әхлакый хөкем ителергә тиеш, ә федераль законнарда каралган очракларда, Кодекс нигезләмәләрен бозу муниципаль хезмәткәргә юридик җаваплылык чараларын куллануга китерә.

6.1.Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нормаларын үтәү аттестацияләр үткәргәндә, югары вазифаларга күрсәтү өчен кадрлар резервын формалаштырганда, шулай ук дисциплинар җәза биргәндә исәпкә алына.

## VII.МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕҢ ТЫШКЫ КЫЯФӘТЕ

7.1. Хезмәт шартларына һәм хезмәт чарасы форматына бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрнең кыяфәте гражданнарның җирле үзидарә органнарына ихтирамлы мөнәсәбәтен булдыруга ярдәм итәргә, рәсмилек, тыйнаклык, традиционлык, пөхтәлек белән аерылып торган гомум кабул ителгән эш стиленә туры килергә тиеш.

7.2. «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тышкы кыяфәтнә төп таләп – киемдә эшлекле стильне саклау тора. Эшлекле костюм төп элемент булып тора.

7.2.1. Ир-атларның тышкы кыяфәтенә таләпләр:

- эшлекле классик костюм, классик күлмәк һәм галстук;

- җәйге вакытта кыска җиңле классик күлмәк кию, шулай ук 25 градустан югары температурада пиджак кимәү рөхсәт ителә;

- классик чалбар, стандарт озынлыкта;

- костюмга килешле галстук;

- кардиган, пуловер, күлмәк белән бергә киелгән жилет рөхсәт ителә;

- оекларның төсе чалбар төсеннән бер тонга карарак булырга тиеш;

- классик стильдәге ботинкалар һәм туфлиләр.

Киңәш ителә:

рәсми шартларда пиджак сәдәфләрен эләктерергә (рәсми чаралар, киңәшмәләрдә чыгыш ясаганда, президиумда һәм башкаларда), иң астагы сәдәф эләктерелми;

- парфюмерииияне күп кулланмаска.

Рөхсәт ителми:

- джинс тукымасыннан тегелгән киемнәр;

- спорт һәм пляж аяк киеме;

- саксыз һәм неопрятная кием;

рәсми чараларда кардиганнар, пуловерлар һәм жилетлар йөртүне (киңәшмәләрдә чыгыш ясаганда, президиумда һәм ТДД.).

- одежда джинсовая;

- обувь спортивная и пляжная;

- пөхтә булмаган кием;

рәсми чараларга кардиганнар, пуловерлар һәм жилетлар кию (киңәшмәләрдә чыгыш ясаганда, президиумда һәм башкаларда).

7.2.2. Хатын-кызларның тышкы кыяфәтенә таләпләр:

- тыйнак төстәге классик эшлекле костюм;

- пастель тондагы блузкалар. Контраст төстәге рәсем булуы мөмкин. Җиңнәрнең озынлыгы нинди булса да ярый, әмма җилкәләр капланган булырга тиеш;

- блуза белән бергә пуловер, кардиган, классик жилет кию рөхсәт ителә;

- тыйнак дизайн һәм төстәге юбка. Озынлыгы: тез уртасыннан 5-8 см.дан да югары түгел һәм балтыр уртасыннан да озын түгел;

- классик фасонлы, җиңе уртача яки озын булган, жакетлы яки пиджаклы тыйнак төстәге күлмәк;

- классик чалбар;

- ябык башлы классик дизайнлы аяк киеме: туфли, полуботинки. Үкчәсе урта биеклектә – 7-8 смнан артык түгел. Җәй көне ачыграк аяк киеме рөхсәт ителә, әмма аның табанны каплавы шарт;

- колготоки төсе киемгә туры килергә тиеш, бер төсле, ажур булмаганнарга өстенлек бирергә кирәк: тән төсендәге, кара, соры, көрән;

- макияж тыйнак, прическа пөхтә, тырнаклар уртача озынлыкта, пөхтә классик маникюр булырга тиеш;

- бизәнү әйберләре: тыйнак аксессуарлар һәм бижутерия.

Киңәш ителә:

- парфюмерииияне уртача куллану.

Рөхсәт ителми:

- джинс тукымасыннан киемнәр;

- артык тар, кыска юбка һәм тирән кисемле юбкалар; үтә күренмәле кием;

- тирән декольтеле блузка һәм күлмәк;

- макси озынлыктагы юбка һәм күлмәк (балтыр уртасыннан озынрак);

- нечкә бретелькалы топлар, җилкәне капламаучы блузалар; пөхтә булмаган кием;

- аркасы ачык һәм биле нык түбән кием;

- шортлар, юбка-чалбар, кыска чалбар; спорт һәм пляж аяк киемнәре;

- күзгә бәреп тора торган бизәнү әйберләре, артык күп бижутерия;

- тыйнак булмаган макияж, ачык төсләрдәге маникюр.

7.2.3. Ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә ирекле стильдәге кием: ирекле фасонлы чалбар, юбка, ачык төстәге свитерлар, джемпер артык бай чәчәкләр, классик төстәге джинс киеме һәм тыйнак дизайн рөхсәт ителә.

Әлеге кагыйдә планлаштырылган рәсми чара, киңәшмә булганда

кулланылмый.

7.2.4. Муниципаль хезмәткәрләргә киңәш ителми:

- пирсинг һәм тәннең ачык өлешләренә татуировка ясату;

- панк- һәм рок-культура элементларын, табигый булмаган төсләрне үз эченә алган экстравагант прическа ясау.